СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 284 от 28.08.2024

На № __________ от ____________

# КАРАР

«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 07 августындагы 144 номерлы Саба муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

**1.** Саба муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 07 августындагы 144 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** 4 пунктларга түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә) :

«5) вазыйфаи бурычларын үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган мәгълүматлардан файдалануга бәйле булган муниципаль хезмәтнең аерым вазыйфаларына билгеләгәндә»;

**1.2.** 10 пунктның 3 пунктчасындагы 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"хезмәт кенәгәсен һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләрне, хезмәт шартнамәсе (контракты) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;»

**2.** Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

Саба муниципаль районы
Башлыгы Р. Н. Минниханов